# КАРАР

**“19” ноябрь 2019 ел** **№ 7**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл жирлеге Өтнә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 19 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Өтнә территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан, Бөек Ватан сугышында катнашканнардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Чернобыль АЭС һәлакәтен бетерүдә катнашканнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Җирлектәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау;

Өтнә авылы: С.Сәйдәш урамы-30м, Г.Тукай урамы-100м.?

« ӘЙЕ» “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 78 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 71 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 69 кеше тавыш бирде;
“Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Өтнә авылында халык җыенын булып узган дип таныырга, халык

жыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Өтнә территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан, Бөек Ватан сугышында катнашканнардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Чернобыль АЭС һәлакәтен бетерүдә катнашканнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Җирлектәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау;

Өтнә авылы: С.Сәйдәш урамы-30м, Г.Тукай урамы-100м.

ӘЙЕ» - “КАРШЫ“-

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Өтнә авылы, С. Сәйдәш урамы, 16а йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сиражетдинов